ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт,
423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 5** **30 ноябрь 2021 ел**

2022 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегендәге Екатериновка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 7 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 15 декабрендә 14.00 сәгатьтә Димтамак авыл җирлегенә керүче Екатериновка торак пунктында Яшел урам, 13 санлы торак йорт адресы буенча урнашкан йорт янында 2022 елда Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Екатериновка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Екатериновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган тормыш иптәшләре, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2000 (Ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

-Екатериновка бистәсендә зират территориясен койма белән уратып алу (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.
4. Әлеге карарны Димтамак авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көннән (халыкка җиткерелгән көннән) үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов